**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

05.08.2022 667-п

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын Татарстан Республикасы законнары белән тәңгәлләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 1318-п номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенә (Л.А.Лукина) югарыда күрсәтелгән Регламент нигезендә эшләрне башкаруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2022 елның 5 августындагы
667-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

### 1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

### 1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр даирәсе

Мөрәҗәгать итүчеләр – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырган, Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затлар, әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, Россия Федерациясе гражданнары булып торучы шәхси эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле булып тиешле вәкаләтләрнең үзенә бирелүен раслый торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә

рәсмиләштерелгән документлар нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат эш итә ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү турында карарлар кабул итү.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык)

Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба КФҮ) аша (әлеге функцияләрне гамәлгә ашырганнан соң) күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасына интеграцияләнгән махсус программа тәэминатын (алга таба – «АСЛН» ФДМС) кулланып рәсмиләштерелгән, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ Законы) $12^1$ статьясының дүртенче өлеше нигезендә билгеләнгән һәм Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының һәм Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның 2021 елның 25 октябрендәге 782/13 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча «XML» һәм «PDF» форматында (алга таба – билгеләнгән форма) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия файлы. Файдалануга тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрнең дәүләт реестрында (алга таба – Дәүләт реестры) лицензияне автомат рәвештә теркәгәннән соң һәм номер беркетелгәч, лицензия Җир астыннан файдаланучылар һәм геологик оешмалар порталында «АСЛН» ФДМС системасында «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты»нда (алга таба – ЛКН) урнаштырыла.

2) Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне рәсмиләштерүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензияне рәсмиләштерүдән нигезле баш тарту турындагы хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).

3) «АСЛН» ФДМС системасында билгеләнгән форма буенча рәсмиләштерелгән, лицензиягә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган, «XML» һәм «PDF» форматларындагы җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымта файлы системада автомат теркәлгәннән соң ЛКН урнаштырыла.

4) Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр кертүдән баш тарту һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертүдән нигезле баш тарту турында Комиссия карарын мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булган очракта аның законлы вәкиленә тапшыра (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).

5) «XML» һәм «PDF» форматында җир асты байлыкларыннан файдалануга яңа лицензия файлын рәсмиләштерү һәм теркәп, номер беркетелгәннән соң ЛКН автомат урнаштыру юлы белән, билгеләнгән форма буенча «АСЛН» ФДМС системасында үзгәртеп рәсмиләштерелгән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия.

6) Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән нигезле баш тарту турында Комиссия карарын мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп карарны җибәрү).

7) Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү) турында карар һәм Дәүләт реестрында лицензия статусын «туктатылды» дип үзгәртү һәм карарны мөрәҗәгать итүчегә кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән яки, тиешле ышаныч кәгазе булган очракта, аның законлы вәкиленә җибәрү (гариза буенча);

8) Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан (чикләүдән) баш тарту һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан нигезле баш тарту турындагы Комиссия карарын мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).

9) Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында карар һәм Дәүләт реестрында лицензия статусын «бетерелде» дип үзгәртү һәм карарны мөрәҗәгать итүчегә кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән яки, тиешле ышаныч кәгазе булган очракта, аның законлы вәкиленә җибәрү (гариза буенча).

10) Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан нигезле баш тарту турындагы Комиссия карарын мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә

тапшыру (яки кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрү).

11) Мөрәҗәгать итүчегә кулына яки, тиешле ышаныч кәгазе булганда, аның законлы вәкиленә лицензия дубликаты бирү.

12) лицензия дубликатын бирүдән баш тарту (карарны заказлы хат белән, тапшыру турында белдерү белән җибәрү).

2.3.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысуллары:

ЛКН, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы (алга таба – Республика порталы) шәхси кабинет аша «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының (алга таба – министр) яисә аның вазифаларын башкаручы затның көчәйтелгән квалифицияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ (электрон документ үрнәге) рәвешендә;

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен «АСЛН» ФДМС системасында https://lk.rosnedra.gov.ru/subsoil адресы буенча ЛКН аша алу өчен мөрәҗәгать итүчегә (юридик затка) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон цифрлы имза рәсмиләштерергә кирәк.

Мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә аңа булган үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымтаны, җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне бирү Дәүләт реестрында теркәлгәннән соң, ЛКН автомат урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү), лицензия статусын үзгәрткәннән соң җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ тиешле язу кертү (лицензия файлына карарны беркетү) юлы белән Дәүләт реестрында һәм ЛКН аша чагылдырыла. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче әлеге карарны кулына алырга мөмкин, яки ул мөрәҗәгать итүче адресына үзе сайлаган юл белән җибәрелергә мөмкин.

Лицензия дубликатын бирү Министрлыкта башкарыла.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон үрнәге шәхси кабинетка автомат рәвешендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гамәлдә булган чор дәвамында электрон документ рәвешендә яки кәгазьдә алырга хокуклы.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга теркәлгән лицензияне рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү чоры – гариза теркәлгәннән соң 36 эш көне, шул исәптән:

- мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү яки мондый хокукны бирүдән баш тарту

турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 18 эш көне;

тиешле карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан кишәрлегеннән файдалану хокукы бирүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү;

- «АСЛН» ФДМС системасында «XML» һәм «PDF» форматында җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия һәм лицензия шартларын әзерләү (рәсмиләштерү) – мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү турында карар кабул ителгәннән соң 18 эш көне.

2.4.2. «АСЛН» ФДМС системасында «XML» һәм «PDF» форматында Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымтаны бирү – гариза теркәлгәннән соң 36 эш көне, шул исәптән:

- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү яки Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 18 эш көне:

- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – тиешле карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә;

- «АСЛН» ФДМС системасында «XML» һәм «PDF» форматында лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткән лицензия кушымтасын әзерләү (рәсмиләштерү) – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар кабул ителгәннән соң 18 эш көне. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә «Җир асты байлыкларыннан файдалану турында» РФ Законының 12[1] статьясының бишенче өлешендәге 1-5 пунктларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертелгән очракта, рәсмиләштерү җир асты байлыкларыннан файдаланучының ризалыгын алганнан соң гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга теркәлгән лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү – гариза теркәлгәннән соң 36 эш көне, шул исәптән:

- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү – гариза теркәлгәннән соң 18 эш көне;

- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – тиешле карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә;

- «АСЛН» ФДМС системасында «XML» һәм «PDF» форматында үзгәртеп

рәсмиләштерелә торган лицензия файлын әзерләү (рәсмиләштерү) – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча карар чыгарылган көннән 18 эш көне.

2.4.4. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү) өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү) яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан (чикләүдән) баш тарту турында теркәлгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү – гариза теркәлгәннән соң 18 эш көне.

2.4.5. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында теркәлгән карарны җибәрү һәм «АСЛН» ФДМС системасына җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату яисә вакытыннан алда туктатудан баш тарту турындагы карарда күрсәтелгән датадан лицензияне дәүләт исәбеннән төшерү турында язу кертү – гаризаны теркәгәннән соң 18 эш көне.

2.4.6. Лицензия дубликаты бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү яки мөрәҗәгать итүчегә лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында белдерү җибәрү – гаризаны теркәгән вакыттан алып 18 эш көне.

2.4.7. Мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымтаны, җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне бирү (Дәүләт реестрына язу кертү һәм «АСЛН» ФДМС системасында ЛКН автомат рәвештә урнаштыру юлы белән дәүләт теркәвенә алу өчен махсус программа тәэминатын кулланып җибәрү карар кабул итү чорын (18 эш көне) һәм тиешле документны әзерләү чорын (18 эш көне) үз эченә ала.

Рәсмиләштерелгән документны (файлны), үзгәртеп рәсмиләштерелгән лицензияне, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымта файлын бирү (ЛКН урнаштыру) Дәүләт реестрында автомат теркәгәннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдаланучының ризалыгын алуны күздә тоткан үзгәрешләр кертелгәндә («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ статьясының 4 өлеше) чагыштырма таблицаны имзалау чоры дәүләт хезмәте күрсәтү чорына керми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү ысулына бәйле түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп);

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Гомумтаралган файдалы казылмаларның ятмаларын эзләү һәм бәяләү, разведкалау һәм чыгару максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корымаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм яраклылыгын бәяләү максатларында һәм (яки) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) түбәндәгеләрне тапшыра:

а) гариза (гарызнамә) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

б) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирү мизгеленә торышын чагылдыра торган һәм эшләрне башлауда планлаштырыла торган сроклар һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турындагы белешмәләрне үз эченә алган аңлатма язуы;

в) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт координаталары системаларын, биеклекләрнең дәүләт системасын һәм дәүләт гравиметрия системасын билгеләү турында» 2016 елның 24 ноябрендәге 1240 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәте карары) белән билгеләнгән геодезия системасында (алга таба – ГСК-2011) җир асты байлыклары кишәрлегенең почмак нокталары географик координаталарын күрсәтеп, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе;

г) мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр мөрәҗәгать итүче булып юридик зат торса);

д) мөрәҗәгать итүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;

е) гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә мөрәҗәгать итүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

ж) кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

з) подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

и) мөрәҗәгать итүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;

к) эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре;

л) кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап,

бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның мөрәҗәгать итүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

м) геологик өйрәнү һәм җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылма чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклы булуын бәяләү максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә – төзелеш объектының күләмнәре турында белешмәләрне үз эченә алган җир асты корылмасын төзүнең расланган проектыннан өземтә;

н) гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан кулланыла торган эчке һәм катнаш («елга-диңгез») елга судноларын «ГЛОНАСС+112» спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС + GPS» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланмалар урнаштыру актының күчермәсе (мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге судноլар файдаланылганда);

о) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, төзәтү, карап тоту буенча эшләр башкару турында шартнамә күчермәсе, – төзелгән шартнамәләр, дәүләт контрактлары нигезендә эшләр уздырылган очракта.

и) 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә карата Министрлык белән төзелгән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга Дәүләт контракты реквизитлары – эшләр Дәүләт контракты нигезендә уздырылган очракта;

р) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектлары исемлеге нигезендә тимер юл транспорты өлкәсендә табигый монополия субъекты тарафыннан төзелгән гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга шартнамә күчермәсе («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $10^1$ ст. 1 өлешенең 1 пункты);

с) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы документ реквизитлары.

2.6.2. Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты суларын эзләү һәм бәяләү яки эчә торган яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты сулары булган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артмаган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны разведкалау һәм чыгару максатларында аларны геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хоукын бирү өлешендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

а) гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

б) мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр мөрәҗәгать итүче булып юридик зат торса);

в) мөрәҗәгать итүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;

г) гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

д) кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

е) подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

ж) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы документ реквизитлары.

з) кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның мөрәҗәгать итүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

и) мөрәҗәгать итүченең яисә җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);

к) эшләрне башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләре (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);

л) су алу скважинасы паспортының күчермәсе (җир асты суларын эзләү һәм чыгару максатында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы биргәндә яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен (булган очракта);

м) җир асты суларын чыгаруның белдерелгән күләмен исәпләү һәм нигезләү (җир асты суларын эзләү һәм чыгару максатында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгәндә);

н) файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнүне уздыру тәкъдимен дә кертеп, файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегеннән файдалану шартлары буенча, эшләрнең төрләрен, күләмнәрен, уздыру срокларын, геологик өйрәнүнең көтелгән нәтиҗәләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнәре, шул исәптән файдалы казылма запасларын үстерү буенча да (җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны эзләү һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә);

о) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында мәгълүмат, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик төзелеше турында белешмәләр, шул исәптән эксплуатацияләнә торган су горизонты турында белешмәләр;

- җир асты суларына булган ихтыяҗны һәм җир асты суларын максатчан куллануны нигезләү;

- су алу корылмасын эксплуатацияләү режимының характеристикасы;

- җир асты суларын җир асты байлыклары кишәрлегендә белдерелгән ихтыяҗ күләмендә чыгару мөмкинлеген нигезләү;

- су әзерләү системасын куллану турында мәгълүмат (булган очракта);

- җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның конструкцияләре һәм билгеләнеше турында белешмәләр;

- чыгарыла торган җир асты суларының санын һәм сыйфатын исәпкә алу һәм контрольдә тоту чаралары турында белешмәләр;

п) РФ Хөкүмәте карары белән билгеләнгән ГСК-2011 су алу скважинасыннан файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлегенең географик координаталары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе;

р) җир асты байлыклары кишәрлегеннән эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында файдалану өчен планлаштырганда, су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халык саулыгы өчен куркынычсызлык шартларына туры килү-килмәве турында санитар-эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе (тәүлегенә кимендә 100 $м^3$ күләмендә чыгарылганда җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны разведкалау һәм чыгару максатларында җир асты суларын разведкалау һәм чыгару яки геологик өйрәнү өчен айдалану хокукы бирелгән очракта, эчә торган максатларда су белән тәэмин итү өчен файдалануга планлаштырылган җир асты байлыклары кишәрлеге).

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән эчә торган су белән тәэмин итү яки бакчачылык коммерциясез ширкәтләрен һәм (яки) яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрен техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару максатларында файдалану хокукы бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

а) гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

б) коммерциясез бакчачылык ширкәте һәм (яки) бакчачылык коммерциясез ширкәте уставы;

в) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында документ реквизитлары;

г) РФ Хөкүмәте карары белән билгеләнгән ГСК-2011 системасында географик координаталарын күрсәтеп, коммерциясез бакчачылык ширкәте һәм (яки) бакчачылык коммерциясез ширкәте территориясендә урнашкан, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлегенең һәм су алу скважиналарының ситуацион планы;

д) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында мәгълүматны үз эченә ала, анда: су әзерләү системасын куллану (булганда), су алу корылмасыннан файдалану режимының характеристикасы, чыгарыла торган җир асты суларының санын һәм сыйфатын исәпкә алу һәм контрольдә тоту чаралары турында белешмәләр, эксплуатацияләнә торган су горизонты турында белешмәләр;

е) су алу скважинасы паспортының күчермәсе;

ж) җир асты суларын чыгаруның белдерелгән күләмен исәпләү;

з) су объектының халык сәламәтлеге өчен имин булган су объектыннан файдалану кагыйдәләренә һәм шартларына туры килүе турында санитар-

эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе (эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатларында җир асты байлыклары кишәрлеген кулланганда).

2.6.4. Мөрәҗәгать итүчегә лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен түбәндәге документлар кирәк:

а) гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта), техник хатаны төзәтү зарур булган очракта, гариза форма буенча тапшырыла (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Лицензиянең гамәлдә булу вакыты озайтылган очракта, гаризада түләү йөкләмәсе реквизитлары күрсәтелә;

б) лицензиягә үзгәрешләр кертү, аларны кертү кирәклеген нигезләп, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булу вакытын үзгәртү буенча тәкъдимнәр (аңлатма язуы);

в) лицензия шартларын план буенча һәм фактта үтәү срокларын күрсәтеп, лицензия алынган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә әлеге шартларның үтәлешен раслый торган документлар һәм материалларны теркәп, лицензия килешүе шартларын үтәү турында, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә лицензия алган көннән башлап, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә башкарылган эшләрнең төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартларын үтәве турында мәгълүмат каралган һәм үтәлгән (үтәлмәгән) таләпләрне күрсәтеп, чагыштырма таблица рәвешендә бирелә.

1. Лицензия бирелгән шартлардан шактый аерылып торган хәлләр барлыкка килгән очракта, аңлатма язуы, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына кагылышлы тәкъдимнәре белән лицензия шартларына үзгәрешләр кертү кирәклеген нигезләргә тиеш.

2. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгару, тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләү кирәклеге турында аңлатма язуында лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту зарурлыгын нигезләү өлешендә аңлатма һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия шартларын бозмавы турындагы мәгълүмат булырга тиеш.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза аның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 3 айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

3. Лицензия кишәрлегенә чикләренә кагылышлы үзгәрешләр булганда, тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатма язуыннан тыш, мәйданын күрсәтеп, ГСК-2011 координаталар системасында билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсен тапшырырга кирәк (үзгәрә торган чикләрне чагылдырып һәм сорала торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталары координаталарын күрсәтеп).

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең мәйданы арттырылган очракта, тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатма язуыннан һәм билгеләнгән таләпләр нигезендә

рәсмиләштерелгән, мәйданы күрсәтелгән, ГСК-2011 координаталар системасында топографик план күчермәсеннән тыш (үзгәрә торган чикләрне чагылдырып һәм сорала торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталары координаталарын күрсәтеп), түбәндәге документлар кирәк:

- файдалы казылма запасларының имин алып бару чикләрен исәпкә алып, файдалы казылма хәзинәләре кишәрлеге чикләрен киңәйтүнең технологик ихтыяҗлары, тау эшкәртмәләренең зарарлы йогынтысыннан саклау зоналары, тау токымнарының зарарлы йогынтысыннан саклау зоналары, табигый объектлар, биналар һәм корылмалар астында саклау циклары контурлары, карьерларның бортлары һәм кисү бортлары һәм җир асты байлыкларының торышына һәм җир өслегенә йогынты ясый торган башка факторлар турында мәгълүмат;
- җир асты байлыкларының аскы өлешендә җир асты байлыклары кишәрлегеннән читтә файдалы казылмаларның файдалы казылма запасларының дәүләт яки территориаль балансына (алга таба – баланс) куелган җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә әлеге файдалы казылма ятмасының бер өлеше булып торуына дәлил;
- балансга куелган файдалы казылмаларның җир асты байлыклары кишәрлегеннән читтә (җир асты байлыкларының түбән өлешеннән тыш) бу файдалы казылма ятмасының бер өлеше булып торуы турында җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә раслама;
- «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ статьясы нигезендә килештерелгән дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәләренә ия булган техник проект турында белешмәләр;
- Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат территориаль фондына тапшырылган геологик хисап турында белешмәләр.

Әлеге нигез буенча үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.05.2012 ел, № 429 карары белән расланган «Җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында нигезләмә»дә каралган тәртиптә мәнфәгатьле министрлыклардан һәм ведомстволардан уңай бәяләмәләр алынганнан соң гамәлгә ашырыла.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең мәйданы киметелгән очракта, тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатма язуыннан һәм билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән, мәйданы күрсәтелгән, ГСК-2011 координаталар системасында топографик план күчермәсеннән тыш (үзгәрә торган чикләрне чагылдырып һәм сорала торган территориянең (географик һәм турыпочмаклы) почмак нокталары координаталарын күрсәтеп), түбәндәге документлар кирәк:

- җир асты байлыклары кишәрлегенең кимәтә торган өлешендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә күрсәтелгән һәм аларга карата билгеләнгән тәртиптә дәүләт экспертизасы уздырылган файдалы казылма запаслары булмаса, җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешеннән баш тартуы;
- җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә түбәндәгеләргә раслама: җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм (яки) файдалы казылмаларны разведкалау буенча җир асты байлыклары кишәрлегендә башкарылган эшләрнең тиешле төр

нәтиҗәләре буенча геологик хисапта расланган җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешен төшереп калдыруга тәкъдим ителә торган геологик объектларны алга таба үзләштерү өчен перспективалы булмавының ачыклануы;

- әлеге кишәрлекнең җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаручы җир асты байлыкларыннан файдаланучының үз (шул исәптән җәлеп ителгән) акчасы хисабына ачылган файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында белешмәләр;

- балanska куелган файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре турында белешмәләр.

4. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының тау (геологик) бүлеп бирү чикләрендә файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалау һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы, юлдаш файдалы казылма җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә күрсәтелмәгән очракта («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 9 статьясындагы 8 өлеше), лицензиягә тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатмадан тыш, файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирергә кирәк («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 29 статьясы).

5. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия рәсмиләштергәндә яки үзгәртеп рәсмиләштергәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтергә кирәк булган очракта, шул исәптән файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләре турындагы белешмәләрдә аңлатма язуында ачыкланган техник хата турында мәгълүмат һәм аны төзәтү кирәклеген нигезләү булырга тиеш. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган лицензия составында документны да теркәргә кирәк.

6. Юридик затның – җир асты байлыкларыннан файдаланучының исеме үзгәргән очракта, тиешле үзгәрешләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә аңлатмадан тыш, билгеләнгән тәртиптә юридик затның гамәлгә кую документларының күчермәләрен бирергә кирәк.

7. Бүлеп бирелгән тауның тәгаенләштерелгән чикләрен таныклый торган документларны (бүлеп бирелгән тау актын һәм график кушымталарны) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә аның аерылгысыз өлеше буларак керткән очракта, бүлеп бирелгән тауның тәгаенләштерелгән чикләрен раслый торган документларның (бүлеп бирелә торган тауның почмак нокталары координаталары исемлеге белән бүлеп бирелгән тауның планы кертелә торган тау бүлеп бирү акты һәм график кушымталар, бүлеп бирелгән тау чикләре планы һәм билгеләнгән формада төзелгән җир асты байлыклары кишәрлеге кисемнәре) оригиналларын тапшырырга кирәк;

2.6.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә дәгъва кылучы юридик зат лицензиянең гамәлдә булу вакыты чыкканчы алты айдан да соңга калмыйча гариза бирә, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүче турында һәм яңадан рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдалану турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, оештыру-хокукый рәвеше, төп дәүләт теркәве

номеры, салым түләүченең идентификация номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры;

- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензиянең төрен, номерын, датасын, җир асты байлыклары кишәрлегенең атамасын, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендәге эшләрнең максатчан билгеләнешен күрсәтеп, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гозер;

- «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $17^1$ статьясында каралган лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезе;

- мөрәҗәгать итүченең үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензиядә каралган, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә үтәлмәгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартларын тулысынча үтәүне үз өстенә алуга ризалыгы.

- лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаучы түләү йөкләмәсе реквизитлары.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү гаризасына түбәндәге материаллар һәм белешмәләр теркәлергә тиеш:

- ышаныч кәгазе, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә гариза мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта;

- юридик затның гамәлгә кую документларының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләре;

- лицензия хуҗасының лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә рөхсәтен раслаучы документ, аны үзгәртеп рәсмиләштерү нигезен күрсәтеп (әгәр гариза тапшырган вакытта лицензия хуҗасы юридик зат статусын саклап калган булса);

- акционерлар реестрыннан өземтә (гариза тапшыручы акционерлык җәмгыятьләре өчен);

- барлык кушымталары белән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия оригиналы.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына күчүнең конкрет нигезенә карап, мөрәҗәгать итүче ТР Министрлар Кабинетының 06.06.2022 № 527 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенең 4 бүлегендәге 4.5 пунктында күрсәтелгән документлар һәм белешмәләрне тапшыра.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының башка затка күчүенең конкрет нигезенә карап, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә түбәндәге документларны һәм белешмәләрне тапшырырга тиеш:

1) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аңа башка юридик затны кушу яисә башка юридик зат белән берләштерү юлы белән үзгәртеп корылганда яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат – юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә башка юридик затка кушу нәтиҗәсендә туктатылган очракта:

- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр;

2) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аны бүлү яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә аннан башка юридик затны аерып чыгару юлы белән үзгәртеп корылган очракта, әгәр яңа оештырылган юридик зат җир асты байлыкларыннан файланаучы элеккеге затка бирелгән лицензия нигезендә эшчәнлекне дәвам иттерергә ниятләсә:

- лицензия алуга дәгъва итүче затның тиешле җир асты кишәрлегенә хокукы чагылдырылырга тиеш булган тапшыру акты (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә);

- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр;

3) юридик зат – җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия нигезендә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә эшчәнлекне дәвам иттерү өчен оештырылган яңа юридик затның гамәлгә куючысы булса:

- яңа юридик затның Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелүен һәм элеккеге юридик зат – бир асты байлыкларыннан файдаланучының өлеше җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкән вакытта мөрәҗәгать итүче капиталында кимендә яртысын тәшкил итүен раслый торган документларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре;

- мөрәҗәгать итүчегә лицензиядә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәт, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә төзекләндерү объектлары мөлкәтеннән файдалану өчен кирәкле мөлкәт тапшырылуы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга (маркшейдер эшләре башкаруга) кирәкле лицензияләр булуы турында белешмәләр;

- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларына һәм квалификацияле белгечләргә ия булуы турында белешмәләр;

4) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – төп җәмгыять булып торган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан аның бүлендек җәмгыяте булып торган юридик затка тапшырылган очракта, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – бүлендек җәмгыять булып торучы җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан аның төп җәмгыяте булып торган юридик затка тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыятьләр статусын раслый торган документларны (төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләрен, акционерлар реестрыннан өземтә, хуҗалык итүче җәмгыятьләр арасындагы килешү күчермәсен яки Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә бүлендек җәмгыять тарафыннан кабул ителә торганк арарларны төп җәмгыять тарафыннан билгели алу мөмкинлеген раслый торган документларның күчермәләрен) тапшыра;

5) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы юридик зат – төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте булып торган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан шул ук төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте булып

торган юридик затка тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыятьләр статусын раслый торган документларны (төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләрен, акционерлар реестрыннан өземтә, хуҗалык итүче җәмгыятьләр арасындагы килешү күчермәсен яки Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә бүлендек җәмгыять тарафыннан кабул ителә торганк ararларны төп җәмгыять тарафыннан билгели алу мөмкинлеген раслый торган документларның күчермәләрен) һәм төп җәмгыятьнең лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә язмача күрсәтмәсен тапшыра.

Шулай ук мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга карата белдерелә торган таләпләргә туры килүе турында, анда җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен тиешле финанс һәм техник чараларның булуы һәм квалификацияле белгечләрнең булуы турында белешмәләр, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясендә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәтнең, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә урнаштырылган объектлар мөлкәте составыннан да, мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган булуы турында мәгълүматлар тапшырылырга тиеш;

6) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль законда каралган тәртиптә эшкуарлык эшчәнлеге субъекты тарафыннан бөлген (банкрот) дип танылган җир асты байлыкларыннан файдаланучының мөлкәтен (мөлкәти комплексын) сатып алганда:

- җир асты байлыкларыннан файдаланучының үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча аны үзгәртеп рәсмиләштерүгә бөлген (банкрот) дип танылган юридик затның – үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучының банкротлыгы турындагы эштә расланган конкурс идарәчесе тарафыннан имзаланган ризалыгы;

- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча бөлген (банкрот) дип танылган җир асты байлыкларыннан файдаланучының кредиторларның гомуми җыелышының яисә кредиторлар комитетының гомуми җыелышының аны үзгәртеп рәсмиләштерүгә ризалык турындагы карары күчермәсе;

- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучыны бөлген (банкрот) дип тану һәм конкурс производствосын ачу турында үз көченә кергән суд карары реквизитлары;

- конкурс идарәчесен, финанс идарәчесен раслау турында суд билгеләмәсе күчермәсе, шулай ук үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча бөлген (банкрот) дип танылган җир асты байлыкларыннан файдаланучының банкротлыгы турындагы эштә расланган конкурс идарәчесе, финанс идарәчесе турында белешмәләр;

- мөлкәт сатып алучының Россия Федерациясе законнары нигезендә барлыкка килгән юридик зат булуы һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә җавап бирүе турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүченең финанс мөмкинлекләре, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен кирәкле квалификацияле белгечләр һәм техник чаралар турында белешмәләре булган документлар);

- җир асты байлыкларыннан файдаланучыга карата банкротлык процедурасы үткәрелүен раслаучы документлар, шул исәптән җир асты байлыкларыннан

файдаланучының банкротлык процедурасы башлануы турында суд карары күчермәсе;

- җир асты байлыкларыннан файдаланучы булган банкрот предприятиесенең мөлкәтен (мөлкәт комплексын) сатып алуны раслаучы документлар (оригиналлар яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермә) һәм бу мөлкәтнең тиешле җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегеннән файдалануга бәйле булуын раслаучы документлар (оригинал яисә расланган күчермә).

- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге буенча файдалануга бирелгән җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматны кабул итү-тапшыру актының күчермәсе, үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан мөрәҗәгать итүчегә карата;

- «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 36.1 статьясында каралган җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылма ятмаларын геологик өйрәнүне тормышка ашыруга проект документларын, файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектын кабул итү-тапшыру акты күчермәсе.

7) консеция килешүе, кайнар су, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларына карата, мондый системаларның «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль законда каралган башка объектларына карата аренда килешүе һәм башка төрле килешүләр төзелгән очракта:

- кайнар су, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларына карата, мондый системаларның «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль законда каралган башка объектларына карата концессия килешүе, аренда килешүе һәм башка төрле килешүләр күчермәсе.

2.6.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм лицензияне дәүләт исәбеннән төшерү өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, мөрәҗәгать итүчегә вакытыннан алда соралган датага кадәр алты айдан да соңга калмыйча, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында гариза тапшырырга кирәк, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешу-хокук рәвеше, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры)

2) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең дәүләт теркәү номеры һәм аны дәүләт теркәвенә алу көне;

3) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының вакытыннан алда туктатылу датасы;

4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату сәбәпләре;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия буенча файдалану шартларын үтәве турында мәгълүмат;

6) тау эшкәртүләрне, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны (җир асты байлыклары кишәрлегендә тау эшкәртүләр, бораулар скважиналары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмалар булган очракта) консервацияләү һәм бетерүнең техник проектын «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ статьясында каралган тәртиптә килештерү турында карар белешмәләре;

7) файдалы казылма һәм җир асты сулары запасларына, «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 29 статьясында каралган куллануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең реквизитлары;

8) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 26 статьясы нигезендә кул куелган, тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларны бетерү яки консервацияләү турында актның реквизитлары.

6, 7, 8 пунктлары буенча мәгълүмат булган очракта бирелә.

2.6.7. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү) өлешендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен, мөрәҗәгать итүчегә, түбәндәге документларны теркәп, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору сәбәпләрен күрсәтеп, гариза тапшырырга кирәк: Җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору турында белдерүе:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешу-хокук рәвеше, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры)

2) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең дәүләт теркәү номеры һәм аны дәүләт теркәвенә алу көне;

3) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору чоры;

4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору (чикләү) сәбәпләре;

5) җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия буенча файдалану шартларын үтәве турында мәгълүмат;

6) тау эшкәртүләрне, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны (җир асты байлыклары кишәрлегендә тау эшкәртүләр, бораулар скважиналары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмалар булган очракта) консервацияләү һәм бетерүнең техник проектын «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ статьясында каралган тәртиптә килештерү турында карар белешмәләре;

7) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 29 статьясында каралган файдалы казылма запасларына һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик

белешмәләргә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе реквизитлары яисә «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 26 статьясы нигезендә кул куелган җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм башка корылмаларны бетерү яки консервацияләү турындагы актның реквизитлары.

6 һәм 7 пунктлар буенча мәгълүмат булган очракта бирелә.

2.6.8. Лицензия дубликаты бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (лицензия хуҗасы) түбәндәгеләрне тапшыра:

- лицензия документларын югалту яки аны югалту турында мәгълүмат белән, лицензия номерын һәм төрен күрсәтеп, гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

- лицензия дубликатын биргән өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән күләмдә дәүләт пошлинасын түләү турындагы документның реквизитлары.

Лицензия «АСЛН» ДМС рәсмиләштерелгән очракта, лицензия дубликаты бирелми. Системадан бастырылган һәм билгеләнгән тәртиптә расланган документның күчермәсе түләү алмыйча, мондый гариза алынганнан соң 10 эш көне эчендә, гариза буенча бирелә.

2.6.9. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) шәхсән, йә почта аша кәгазьдә, йә электрон документ формасында электрон почта аша;

2) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә (әлеге функцияне гамәлгә ашырганнан соң) электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендәге Республика порталы аша;

3) ЛКН аша электрон документ формасында (әлеге функцияне тормышка ашырылганнан соң).

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, шулай ук әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында бар.

Гаризага җир асты байлыкларыннан файдаланучы - юридик зат исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслаучы документ теркәлергә тиеш (мондый физик зат җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат исеменнән ышанычнамәдән башка гамәл кылу хокукына ия булуга нигез булган физик затны билгеләү турында яисә сайлап алу турында карар яки боерык күчермәсе) (алга таба – җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның җитәкчесе). Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы исеменнән башка зат эш итсә, гаризада шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат исеменнән (булган очракта) һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның җитәкчесе (юридик зат өчен) яки җир асты байлыкларыннан файдаланучының башка вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган гамәлләр башкаруга ышанычнамәнең төп нөсхәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышанычнамә җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, гаризада шулай ук мондый затның

вәкаләтләрен раслаучы документ та булырга тиеш.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә (мөрәҗәгать итүченең мөһере белән яки нотариаль яктан) танықланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Кәгазьдә бирелгән гариза мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) (юридик зат өчен) беркетелергә һәм мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталында шәхси кабинетында гаризаның кабул ителүен һәм гаризаны тапшыру датасы буенча раслама ала, анда гаризаны теркәү номеры һәм кабул итү датасы күрсәтелгән була.

Гаризаны Республика порталы яки ЛКН (әлеге функция гамәлгә ашырылганнан соң) аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче электрон чыганакта (оптик CD дискысы яки DVD дискысы, тышкы USB-туплагыч яисә SSD-туплагыч) мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затларның 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә  электрон имзасы белән имзаланган электрон формадагы документлар рәвешендә тапшыра.

Мөрәҗәгать итүчеләр (шәхси эшкуарлар) гаризага гади электрон имза белән кул куя.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – бердәм система) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig  форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6.10. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында өземтә яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язулары кәгазе;

- гариза тапшыручы шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм

дәүләт реестрыннан өземтә яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры язулары кәгазе;

- мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән);

- салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсеннән);

- җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт контракты күчермәсе (күрсәтелгән эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарган очракта);

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халык саулыгы өчен куркынычсыз булган су объектыннан файдалану шартларына туры килүе турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттән (алга таба – Роспотребнадзор) санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе;

- дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акчаларның алынуы турында турында белешмәләр (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе).

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.6 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен югарыда аталган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү, лицензия дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.7.2. Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән аукцион үткәрмичә файдалану хокукын алу өчен гаризаны кабул итүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

а) лицензия алуга гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән очракта;

б) гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда;

в) мөрәҗәгать итүче җир асты байлыкларыннан файдалануны нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса;

г) мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә.

2.7.3. Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән аукцион үткәрмичә файдалану хокукын алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту турындагы карар Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында Карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.7.4. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Лицензия рәсмиләштерүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон багланышлар кысаларында алына торган документлардан яисә Министрлык карамагындагы документлардан тыш, әлеге Регламентның 2.6.1, 2.6.2, 2.6.3 пунктларында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны тапшырмау тора.

2.8.3. Лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон багланышлар кысаларында алына торган документлардан яисә Министрлык карамагындагы документлардан тыш, әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны тапшырмау;

- срокны озайту өлешендә, лицензиянең гамәлдә булу срогы чыкканчы 3 айдан да азрак вакыт эчендә үзгәрешләр кертү турында гариза бирү («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 10 статьясы);

- җир асты байлыкларыннан файдаланучы мөрәҗәгать иткән датага җибәрелгән бозулар турында язмача белдерү җибәрелгән һәм гамәлдә булса, мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә шул шартларга үзгәрешләр кертүдән баш тартыла («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ ст.)

2.8.4. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон багланышлар кысаларында алына торган документлардан яисә Министрлык карамагындагы документлардан тыш, әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны тапшырмау;

- җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыкларыннан

файдалану шартларын бозган очраклар турында гамәлдәге язма белдерү булуы («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 17[1] ст.);

- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы туктатылган булса ( «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 20[1] ст.);

- җир асты байлыкларыннан файдаланучыны, «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 17[1] статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында каралган нигез буенча җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы күчү очракларыннан тыш, бөлген (банкрот) дип тану

- юридик затны – җир асты байлыкларыннан файдаланучыны бетерү турында карар кабул итү – ликвидацияләү комиссиясе тарафыннан юридик затны – җир асты байлыкларыннан файдаланучыны бетерү турында хәбәр бастырылган көннән башлап;

- әгәр лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә гариза лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы алты айдан да соңга калмыйча тапшырылса («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 12[1] ст.);

- үзгәртеп рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән шартларга һәм таләпләргә туры килмәсә.

2.8.5. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту өчен шушы Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны, Министрлык карамагындагы документлардан тыш, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында гаризаны җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату датасына кадәр алты айдан да соңга калмыйча тапшыру нигез була;

2.8.6. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан (чикләүдән) баш тарту өчен, Министрлык карамагындагы документлардан тыш, шушы Регламентның 2.6.7 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны тапшырмау нигез була;

2.8.7. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия дубликатын бирүдән баш тарту өчен, акчалар керү турында ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә расланган мәгълүматның булмавы, ә атап әйткәндә, лицензия дубликатын биргән өчен дәүләт пошлинасы (Федераль казначылык идарәсе) нигез булып тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы күләме Россия Федерациясе Салым кодексы белән билгеләнгән:

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү – 7500 сум;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 750 сум;

- үзгәрешләр кертү (җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогы озайтылган очракта) – 750 сум.

- лицензия дубликаты бирү – 750 сум.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан акча күчерү юлы белән, акчасыз исәп-хисап рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Акча күчерү өчен реквизитлар:

Алучы: ТР буенча ФКИ, (ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, шәхси счет: 04112001010)

Казначылык счеты номеры 03100643000000011100

Бердәм казна счеты 40102810445370000079

Түләү алучының банкы: – Россия Банкының ТР Милли банкы бүлекчәсе//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре

БИК 019205400

ИНН 1659036508

КПП 165901001

ОКТМО 92701000

КБК 701 1 08 07082 01 1000 110

Түләүнең билгеләнеше: җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү / җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү / җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту/ лицензия дубликаты бирү өчен дәүләт пошлинасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документка үзгәрешләр кертелгән очракта, Министрлык һәм (яки) Министрлыкның вазыйфаи заты гаебе белән кертелгән хаталарны төзәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

2.10.3. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

Кәгазьдә яисә электрон документ формасында, электрон почта аша кергән гариза гариза кергән мизгелдән бер көн эчендә теркәлә.

Гаризаны Республика порталы, «АСЛН» ФДМС системасында ЛКН аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында, ЛКН һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

Ял (бәйрәм) көнендә Республика порталы, «АСЛН» ФДМС системасында

ЛКН аша электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча яраклаштырып булмаса, аларны реконструкцияләгәнчегә һәм капиталь ремонтлаганчыга кадәр, Министрлык Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренең берсе белән килештереп, мумөикн булган очракта, инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына керүен тәэмин итү өчен чаралар күрергә яисә кирәкле хезмәтләрне инвалидның яшәү урыны буенча яисә дистанцион режимда күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш.

2.12.4. Автотранспорт чаралары парковкаларында инвалидларның махсус

автотранспорт чараларын кую өчен кимендә бер урын бирелә.

Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» тану билгесе билгеләнергә һәм әлеге транспорт чаралары турындагы мәгълүмат инвалидларның федераль реестрына кертелергә тиеш.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган биналарның тиешле санда булуы;

3) мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

4) Электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

5) Министрлык биналарын һәм бүлмәләрен инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген бирә торган башка шартлар үтәлешен тәэмин итү;

6) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

7) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы порталында һәм ЛКН электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар биргәндә шәхси кабинет аша электрон рәвештә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуларга карата нигезле шикаятьләр булу.

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталындагы шәхси кабинетта, Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яки телефон аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге, алдан авторизация узмыйча гына, Порталдагы «шәхси кабинет» аша гамәлгә ашырыла.

«Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң, мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша түбәндәге мөмкинлекләрне ала:

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирергә; - дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат алырга.

Республика порталындагы «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата башка таләпләр

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алып;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 72 пункты нигезендә танылканган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасының «Электрон мәгариф» мәгълүмат системасы, Республика порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә;

2.14.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында, ЛКН (әлеге функция гамәлгә ашырылганнан соң) гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелә (әлеге функцияләрне гамәлгә ашырганнан соң).

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексл гариза составында дәүләт

хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Җир асты байлыкларыннан файдалануны автоматлаштырылган лицензияләү системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы («АСЛН» ФДМС);

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү, аларны теркәү;

3) гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны карау;

4) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү (Министрлык карарын әзерләү һәм раслау), дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны рәсмиләштерү);

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү яки җибәрү.

3.1.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта (шул исәптән электрон) аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында консультация алырга хокуклы.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Әгәр гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга тели икән, Министрлык мөрәҗәгать итүчене язмача консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләү.

3.1.2. Гаризаны һәм документларны кабул итү, аларны теркәү.

3.1.2.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) шәхсән кәгазь чыганакта яисә почта аша заказлы хат белән, яисә электрон рәвештә, Министрлыкның eco@tatar.ru электрон почтасына җибәреп яисә гади электрон имза яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында Республика порталы, ЛКН (әлеге функцияләр гамәлгә ашырылганнан соң) аша әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гариза тапшыра.

3.1.2.2. Мөрәҗәгать итүче исеменнән башка зат эш иткән очракта, гаризада шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләр башкаруга ышанычнамә оригиналы да булырга тиеш, ул мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) белән таныкланган һәм мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки мөрәҗәгать итүче вәкаләт биргән башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган булырга тиеш (яисә оригиналын күрсәтү шарты белән, ышанычнамә күчермәсе тапшырыла).

3.1.2.3. Республика порталы аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизацияләнә;

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү белешмәсен раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.9 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.1.2.4. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Бүлек белгече катнашында Республика порталы аша карау өчен документлар алынган очракта:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Республика порталына юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булганда, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Документлар кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына гариза кергән датадан бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

3.1.2.5. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Бүлек белгече катнашында, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почта аша карап тикшерүгә документлар алынганнан соң:

Комплектлылыкны тикшерә;

гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итү һәм «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон документ әйләнеше) терки;

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) гаризаның күчермәсен документларны кабул итү датасы турында тамгалап (шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) бирә яисә, телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, алынганда теркәлгән номеры турында хәбәр итә;

документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә (шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта). Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

3.1.2.6. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү факты административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырылган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә этәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, КФҮ аша күрсәтелә (әлеге функцияләрне гамәлгә ашырганнан соң).

3.1.3. Гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны карау.

3.1.3.1. Гаризаны «Электрон документ әйләнеше» системасында теркәлгәннән соң һәм министр караганнан соң гариза җир асты байлыкларыннан файдалану

мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) җибәреләә, ул эшне җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгына җибәрә, гаризаны аны карау буенча чараларны оештыру өчен бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каралган һәм Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм аңа беркетелгән документлар.

3.1.3.2. Бүлек җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каралган һәм Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм аңа беркетелә торган документлар.

3.1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара гариза формалаштыру һәм җибәрү.

Алынган гариза һәм аңа теркәлгән документлар алыну нигезендә Бүлек белгече, әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булсалар, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган тиешле дәүләт органнарына әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында гаризалар әзерли һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС системасы) ярдәмендә аларны җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: анализланган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.1.5. Соратып алына торган мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр тарафыннан белешмәләр бирү.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән, 3.1.4 пунктта күрсәтелгән гариза нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: алынган документлар (белешмәләр) яки Министрлыкка җибәрелгән баш тарту турында белдерү.

3.1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү

3.1.6.1. Алынган гариза һәм аңа теркәлгән документлар һәм, шул исәптән ВЭХС системасы аша алынган белешмәләр нигезендә Бүлек белгече тапшырылган документларны әлеге Регламентның 2.6 пунктына туры килү-килмәве буенча анализлый һәм электрон документ әйләнеше аша Бүлек җитәкчесенә (ул булмаса – Бүлек җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә, түбәндәге очракларда:

а) 2.8.2, 2.8.7 пунктта күрсәтелгән нигезләр булмаганда, Министрлык боерыгы проекты:

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

- лицензия дубликатын бирү турында.

б) әлеге Регламентның 2.8.2, 2.8.7 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда – хат:

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирүдән баш тарту турында;

- лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында.

Лицензия дубликатын рәсмиләштергәндә билгеләнгән формадагы бланкта лицензия дубликатын рәсмиләштерә һәм анда «Дубликат» штампын куя яисә, лицензия дубликаты бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хат проекты әзерли (Регламентның 2.8.7 пункты).

3.1.6.2. Лицензиядә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерүгә заявкаларны карагандa, карар Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү комиссиясе тарафыннан кабул ителә («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ ст.)

Әгәр гариза лицензиянең гамәлдә булу срогын озайткан очракта (лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамланырга кимендә 3 ай кала) яисә лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамланырга кимендә 6 ай кала (лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән очракта) яисә шушы Регламентның 2.6.4, 2.6.5 пунктларында күрсәтелгән документлар булмаган очракта, мондый гариза Комиссиягә карау өчен юллама булырга тиеш түгел. Гариза бирүчегә нигезле баш тарту җибәрелә.

Бүлек белгече Комиссия каравына бирү өчен документлар пакетын формалаштыра һәм аның әгъзаларына өйрәнү өчен җибәрә.

Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Министрлык боерыгы белән раслана. Әлеге Регламентның 2.6.4, 2.6.5 һәм 3.1.5 пунктлары нигезендә алынган белешмәләр (документлар) нигезендә Комиссия җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында карар кабул итә.

Комиссия карары, «Электрон имза турында» федераль закон таләпләре нигезендә, утырышта катнашучыларның барысы да электрон имза кулланып, комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

в) әлеге Регламентның 2.8.3, 2.8.4 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, Комиссия утырышы беркетмәсе проекты:

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында.

г) әлеге Регламентның 2.8.3, 2.8.4 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда – Комиссия утырышы беркетмәсе проекты:

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында.

3.1.6.3. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору (чикләү) буенча заявкаларны караганда, карар Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яисә чикләү комиссиясе тарафыннан кабул ителә («Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $21^1$ ст.).

Бүлек белгече Комиссия каравына бирү өчен документлар пакетын формалаштыра һәм аның әгъзаларына өйрәнү өчен җибәрә.

Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия әлеге Регламентның 2.6.6, 2.6.7 һәм 3.1.5 пунктлары нигезендә алынган белешмәләр (документлар) нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору (чикләү) мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында карар кабул итә.

Комиссия карары, «Электрон имза турында» федераль закон таләпләре нигезендә, утырышта катнашучыларның барысы да электрон имза кулланып, комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

д) әлеге Регламентның 2.8.5, 2.8.6 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, Комиссия утырышы беркетмәсе проекты:

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү) турында.

е) әлеге Регламентның 2.8.5 һәм 2.8.6 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда, Комиссия утырышы беркетмәсе проекты:

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан (чикләүдән) баш тарту турында.

Әлеге пунктларда билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.5 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 7 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына (ул булмаганда – Бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручыга) килештерү өчен юлланган карар проекты.

3.1.6.4. Бүлек башлыгы Комиссия утырышы беркетмәсе проектын килештерә һәм аны Министрлыкның структур бүлекчәләре башлыкларына (Комиссия әгъзаларына, Комиссия карары кабул ителгән очракта) килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.6.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм

Министрлыкның структур бүлекчәләре башлыкларына яисә Комиссия әгъзаларына (Комиссия карары кабул ителгән очракта) килештерүгә юнәлдерелгән Министрлык карары проекты.

3.1.6.5. Министрлыкның структур бүлекчәләре башлыклары (Комиссия әгъзалары) Министрлык карары проектын килештерәләр, шуннан соң ул электрон документ әйләнеше системасы аша министр урынбасарына килештерүгә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.6.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның структур бүлекчәләре башлыклары яки Комиссия әгъзалары тарафыннан килештерелгән һәм министр урынбасарына килештерүгә юнәлдерелгән Министрлык карары проекты.

3.1.6.6. Министр урынбасары (ул булмаганда – министр урынбасары вазыйфаларын башкаручы):

а) түбәндәге проектны килештерә һәм имзалау өчен министрга җибәрә:

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында боерык;

- лицензия дубликаты бирү турында боерык;

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирүдән баш тарту турында хат;

- лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат.

б) Комиссия утырышы беркетмәсен раслый:

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату (чикләү) турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатудан (чикләүдән) баш тарту турында;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.6.5 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

1. Комиссия утырышы беркетмәсе:

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында;
- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату (чикләү) турында;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында;
- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту турында;
- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатудан (чикләүдән) баш тарту турында;
2. Килештерелгән һәм министрга кул куюга юнәлдерелгән проект:
- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында боерык;
- лицензия дубликатын бирү турында боерык;
- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирүдән баш тарту турында хат;
- лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат.
3.1.6.7. Министр (ул булмаганда – министр вазыйфаларын башкаручы зат) раслый:
- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында боерык;
- лицензия дубликатын бирү турында боерык;
- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирүдән баш тарту турында хат;
- лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат.
Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның расланган карары (боерык, беркетмә, хат).

3.1.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү яки җибәрү

3.1.7.1. Министр яисә министр урынбасары тарафыннан расланган карар теркәлгәннән соң, Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге аша мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә яисә шәхсән тапшырыла:
- лицензиянең дубликатын бирү турында боерык һәм рәсмиләштерелгән лицензия дубликаты;
- лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында хат;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү турында хат;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы

беркетмәсен җибәрү турында хат.

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү турында хат;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатудан баш тарту турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү турында хат;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату (чикләү) турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү турында хат.

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатудан (чикләүдән) баш тарту турында карар кабул итү буенча Комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү турында хат.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Министрлыкта, электрон почта аша, ЛКН аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон үрнәге шәхси кабинетка автомат рәвешендә җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Республика порталын, ЛКН кулланып мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны юллау (бирү).

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору (чикләү), җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату турында карар лицензия статусын үзгәртү юлы белән «АСЛН» ФДМС лицензияләр реестрында тиешле язу кертү (лицензия файлына карарны беркетү) юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзгәртелгән статус Лицензияләр реестрында һәм «АСЛН» ФДМС системасында ЛКН аша чагылдырыла.

Бүлек белгече бирелгән лицензияләр журналында имзалатып, лицензия дубликаты бирү турында боерык белән берлектә мөрәҗәгать итүчегә рәсмиләштерелгән лицензия дубликатын яисә лицензия дубликаты бирүдән баш тарту турында хат бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүче адресына җибәрелгән (ЛКН, Республика порталындагы шәхси кабинетта урнаштырылган яисә җитәкчегә (законлы вәкилгә) имзалатып бирелгән) Министрлык карары яисә лицензия дубликаты.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.1.7.2. Әлеге Регламентның 3.1.6 пунктының б), г), е) пунктчаларында күрсәтелгән очракта, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итүче, баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң, әлеге Регламентның 3.1.1-3.1.2 пунктларында каралган тәртиптә Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.1.7.3. Министр яисә министр урынбасары тарафыннан расланган карар, түбәндәгеләр рәвешендә:

- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында боерык;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Комиссия утырышы беркетмәсе;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында Комиссия утырышы беркетмәсе;

документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге аша аны әзерләгән Бүлек белгеченә җибәрелә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән боерык (беркетмә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.1.7.4. Лицензиягә «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ статьясының бишенче өлешендәге 1-5 пунктларда (әлеге Регламентның 2.6.4 пунктының 1-5 пунктчалары) каралган үзгәрешләр кертелгән очракта, Бүлек белгече кертелә торган үзгәрешләрнең чагыштырма таблицасын төзи һәм чагыштырма таблицаны имзалау зарурлыгы турында җир асты байлыкларыннан файдаланучыга почта аша (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат яисә рәсми электрон почта адресына) җибәрү юлы белән хәбәр итә.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр турында билгеләнгән тәртиптә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә бирелә торган һәм аңа тәкъдим ителә торган үзгәрешләр турында мәгълүмат җибәрелгән көннән алып, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең тиешле бүлегенең гамәлдәге редакциясен күрсәтеп, җир асты байлыкларыннан файдаланучы Министрлык адресына (Министрлыкның электрон адресын яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган Министрлыкның вазыйфаи затының электрон почта адресын кулланып яисә заказлы хат аша) 10 эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелә торган үзгәрешләрне килештерү турында яки җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелә торган үзгәрешләрне килештерүдән баш тарту турында җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле вәкиле имзалаган хатны җибәрә.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр турында мәгълүмат җибәрү датасыннан 10 эш көне эчендә имзаланган чагыштырма таблица тапшырылмаган очракта, лицензиягә үзгәрешләр килештерелми. «XML» һәм «PDF» форматындагы файл рәвешендәге «АСЛН» ФДМС системасында лицензиягә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымта рәсмиләштерелми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.1.7.3 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучының чагыштырма таблицага кул кую срогы дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

3.1.7.5. Бүлек белгече, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымта әзерләү өчен (законнарда билгеләнгән очракларда җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан килештерелгән чагыштырма таблица алынганнан соң) Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне исәп-хисап ясау өчен җаваплы бүлегенә җир асты байлыкларының белдерелгән кишәрлеге буенча икътисадый исәпләмә сорап, гариза юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда икътисадый исәпләмә ясау турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгать.

3.1.7.6. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне исәпләү өчен җаваплы булган Бүлекнең вазыйфаи заты икътисадый исәп-хисап әзерли һәм хезмәт язуын Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.1.7.5 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең әзерләнгән икътисадый исәпләмәсе.

3.1.7.7. Икътисади исәп-хисап алганнан соң бүлек белгече («АСЛН» ФДМС системасында) проект әзерли (рәсмиләштерә) :

- лицензия файлы;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия файлы;

- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кушымта файлы.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач 9 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: «АСЛН» ФДМС системасында «XML» һәм «PDF» форматында рәсмиләштерелә (үзгәртеп рәсмиләштерелә) торган лицензия проекты һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары яки лицензиягә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымта проекты.

3.1.7.8. Бүлек белгече «АСЛН» ФДМС аша рәсмиләштерелә (үзгәртеп рәсмиләштерелә) торган лицензия проектын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары проектын яки лицензиягә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган кушымта проектын килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.7.7 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: «АСЛН» ФДМС системасы аша әзерләнгән һәм килештерүгә җибәрелгән лицензия проекты яки лицензиягә кушымта проекты (үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта).

3.1.7.9. «АСЛН» ФДМС системасыннан шәхси файдалану мөмкинлеге булган затлар лицензия файлын яки лицензия кушымтасын тикшерәләр. Лицензияне тикшерү верификацияне һәм лицензия файлын тутыруның төгәл булу-булмавын тикшерүне күздә тота (кәгазь рәвешендәгесенә виза салу кебек).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.7.8 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм министрга кул куюга җибәрелгән рәсмиләштерелә торган лицензия (үзгәртеп рәсмиләштерелә торган) файлы яки лицензия кушымтасы файлы.

3.1.7.10. Министр (ул булмаганда – министр вазыйфаларын башкаручы зат) «Электрон имза турында» федераль закон таләпләре нигезендә электрон имзадан

кулланып, «АСЛН» ФДМС системасында түбәндәгеләрне имзалый:

- рәсмиләштерелә торган лицензия файлы;
- үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия файлы;
- лицензия кушымтасы файлы.

«АСЛН» ФДМС лицензияләр рәсмиләштергәндә, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын имзалау каралмаган.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.7.9 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган лицензия яки җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясе кушымтасы файлы.

3.1.7.11. Файдалануга тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлекләренең дәүләт реестрында язу кертү юлы белән лицензия файлын, лицензиягә кушымтасы файлын һәм «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 28 статьясында каралган лицензияләрне дәүләт теркәвенә алу министр (ул булмаганда – министр вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзаланганнан соң системада автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.1.7.10 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.1.8. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында гариза бирелгән ысулга карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм аны ЛКН, Республика порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге турында Республика порталындагы шәхси кабинеты аша, электрон почта ярдәмендә хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: «АСЛН» ФДМС системасында Дәүләт реестрында теркәлгән һәм, гариза бирелгән ысулга карап, ЛКН яки Республика порталына «XML» һәм «PDF» форматында җибәрелгән лицензия яки лицензия кушымтасы файлы.

Билгеләнгән тәртиптә расланган кәгазьдә лицензия күчермәсе җир асты байлыкларыннан файдаланучыга гариза нигезендә бирелергә мөмкин (җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан тиешле гариза алынган көннән 10 эш көне эчендә, ләкин җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан 5 эш көненнән дә иртәрәк түгел).

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Административ регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контроль тәртибе һәм формалары

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту рәвешләре булып тикшерү үткәрү һәм эш алып бару тора;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Административ регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен үтәү өчен шәхсән җаваплы булалар.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның шәхси җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә беркетелә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту даими, һәрьяклы һәм объектив булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм тәртибен камилләштерү буенча тәкъдимнәр, тәкъдимнәр белән индивидуаль һәм күмәк мөрәҗәгатьләр, шулай ук вазыйфаи затлар тарафыннан административ регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларны бозу турында белдерү һәм шикаятьләр җибәрергә хокуклы.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү

өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы караламган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Республика порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы орган, вазыйфаи зат яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органның, органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 көн эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш көн эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Үрнәк

Оешма бланкы

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

## Аукцион үткәрмичә генә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы алу өчен гариза

________________________________________________________________
җир асты байлыклары кишәрлегенең (ятмасының) атамасы

1. Мөрәҗәгать итүче ______________________________________________
юридик затның исеме, җитәкчесенең ФИА (соңгысы – булган очракта)
________________________________________________________________

2. Дәүләт теркәве кодлары һәм реквизитлары:
________________________________________________________________
________________________________________________________________
ИНН, ОГРН, ОКПО, ОКОНХ, ОКОГУ, БИК, ОКАТО, ОКВЭД һ.б.
________________________________________________________________

3. Юридик адресы:
________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең почта адресы:
________________________________________________________________

телефон: (код) ____________________, телефакс: (код)__________________
e-mail (булган очракта): ____________________________________________

4. Мөрәҗәгать итүченең эшкуарлык максаты, билгеләнгән эшләр исемлеге:
______________________________________________________________

җир асты байлыкларыннан файдалану максатлары, гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеге нигезендә файдалы казылма төре күрсәтелә

______________________________________________________________,

эшләрне үткәрү вакыты: ____________________________________________

______________________________________________________________

5. Банк реквизитлары: ________________________________________

счет номерлары, банк исемнәре

______________________________________________________________

6. Документлар исемлеге:

1) ___________________________

2) ___________________________

3)________________________

…_

Предприятие

җитәкчесе:____________________________________________________

(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) М.У.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Үрнәк

Татарстан Республикасы экология
һәм табигать ресурслары
министрына
___________________________
кемнән:
________________________________
*Җитәкченең Ф.И.А.(соңгысы – булган очракта), предприятие исеме*

лицензия сериясе__________№___________
җир асты байлыклары кишәрлеге_________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
______________________________________________________________
*(хезмәтнең атамасы)*
Язылган:__________________________________________________
Дөрес мәгълүмат:
______________________________________________________________
Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.
Түбәндәге документларны терким:
1.____________________________________________________
2.____________________________________________________
Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:
- адреска электрон документ җибәрү юлы белән
E-mail: ________________________________________;
- кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша хәбәр итүне сорыйм
түбәндәге адрес буенча:______________________________________________

________________________________________(_____________________)
*(дата)* *(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))*

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Үрнәк

Оешма бланкы

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме
(соңгысы – булган очракта)

Җиб. №

Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр кертү турында гариза

____________________________________________________________________________________

*(лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасы, номеры, төре, датасы)*

1. Мөрәҗәгать итүче: ___________________________________________________
____________________________________________________________________________________

*(юридик зат исеме һәм оештыру-хокукый форма, җитәкченең ФИА)*

2. ИНН Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП) Төп дәүләт теркәү номеры

3. Юридик затның урнашу урыны (почта адресы):

Тел.: ___________________________ e-mail:_____________________________
______

____________________________________________________________________________________

*(җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме, җир асты байлыклары кишәрлегендә эшләрнең максатчан билгеләнеше)*

_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
___________

4. Кертелә торган үзгәрешләрнең нигезе һәм кыскача тасвирламасы (*үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә торган лицензия бүлеген күрсәтеп*):

_________________________________________________________________________
_____

5. Дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаучы түләү йөкләмәсе реквизитлары *(лицензия срогы озайтылган очракта)*:

6. Документлар исемлеге:
1) ____________________________
2) ___________________________
3)________________________
…

Предприятие
җитәкчесе:_____________________________________________________________
(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-60 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе | 267-68-60 | Samat.Vahitov@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе | 267-68-68 | Lyudmila.Lukina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |